РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**РЕШЕНИЕ**
18 март 2020 ел

**КАРАР**
№ 4

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 июнендәге 9 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү» һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану турында , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 15 декабрендәге 1572 номерлы карары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына карата Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү нормаларын һәм кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 июнендә кабул ителгән 9 нчы номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең 2 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«каты коммуналь калдыкларны чыгару» - каты коммуналь калдыкларны урыннардан (мәйданчыклардан) аларны туплау урыннарыннан алып каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган объектларга кадәр транспортлау;

2) 10.5 пунктының 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары янында (торак, иҗтимагый һәм житештерү бинарлары, төзелеш һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан), ял итү урыннары , I, II группа инвалидлары идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковка өчен кимендә 10 процент урын (бер урынннан да ким түгел) бүлеп бирелә. III группа инвалидлар арасыннан

гражданнарга әлеге өлеш нормалары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тарала. Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» тану билгесе куелырга тиеш һәм әлеге транспорт чаралары турында мәгълүмат федераль инвалидлар реестрына кертелергә тиеш.».

2020 елның 1 июленнән 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү» һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» әлеге пункт яңа редакциядә бәян ителәчәк.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Илексаз авыл җирлеге
Советы Рәисе Ф.М. Гыйльфанов